**«Кояшкай» дан җылылык алып кайттык!»**

**“Балалар- балаларга” акциясен каршылап**

**“Ал җилкәннәр” һәм “Кояшкай” тимур отрядларының чираттагы тукталышы – “Кояшкай” реаблитация үзәге.**

**Әлеге дәвалау йорты турында әле без ишетеп кенә белә идек. Кама елгасы яр буена диярлек сыенып утырган үзәк- тылсымлы йорт, ә андагы табиблар һәм хезмәткәрләр могъҗиза тудыручылар булып күңелгә кереп калды.**

**Реаблитация үзәгендә 60 лап бала дәвалана икән. Нәниләр өчен монда барлык шартлар да тудырылган. Нинди генә дәвалау аппаратлары юк монда, нинди генә алымнар белән дәваламыйлар. Сабыйларга яраклы җиһазларны да каян гына табып бетергәннәр. Безне хезмәткәрләрнең нәниләргә һәм үзара булган игътибары, җылы мөнәсәбәте соклан-дырды. Тагын безне гаҗәпләндергәне шул булды: монда дәваланучы-лар нәни куллары белән төрле материаллардан ниләр генә эшләми дә, нинди генә могъҗизалар тудырмый икән! Кул эшләрендәге осталык һәм нәфислек, ачык һәм якты төсләр күңелләрне җылыта, кәефләрне күтәрә. Нарасыйлар күңелендәге яктылык, әйтерсең, үзләренең кул эшләренә күчкән. Бу матурлыкны язып кына аңлатып булмый. Ба-ларны авыру дип атарга тел әйләнми!**

**Сабыйларга без концерт- тамаша бүләк иттек. Алар һәр чыгышы-бызне яратып кабул итте, озаклап кул чаптылар. Безнең белән бик теләп фотога төштеләр.**

**Бу очрашудан үзебезгә сабак алып, кылган изге гамәлләребезгә сөенеп һәм күңелләргә рәхәтлек алып кайттык.**

**Изгелек үрнәге булган “Кояшкай” реаблитация үзәге (ГАУ УСО РЦДиП “Солнышко” коллективына һәм аның җитәкчесе М.А. Беловага рәхмәтебезне белдерәбез.**

**“Ал җилкәннәр” тимур отряды әгъзасы Илалетдинов Алмаз,**

**М. Вахитов исемендәге 2 нче гимназия.**




СОЛНЫШКО
Добро пожаловать!
ВНИМАНИЕ




Не делайте из ребенка
кумира: когда он вырастет,
он потребует жертв.
Не воспитывайте
детей, все равно они
будут похожи на вас.
Воспитывайте себя.








Учись у солнца
И каждому с любовью















































только
для тебя!




















СОЛНЫШКО
Рәхим итегез!
Добро пожаловать!





